МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.11.2013 № 672

г.Казань

"Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында" 12 ноябрь, 2007 ел, №346 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

БОЕРЫК БИРӘМ:

"Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында" 12 ноябрь, 2007 ел, №346 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

"Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясындагы 2 өлешенең 87 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау

министрлыгының түбәндәге вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.42 статьясында, 18.15 статьясының 3 өлешендә, 19.5 статьясының 1 өлешендә һәм 19.7 статьясында күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә хокуклы:

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары;

министрның халыкны эш белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча урынбасары;

эш белән тәэмин итүнең актив формаларын үстерү бүлеге начальнигы;

эш белән тәэмин итүнең актив формаларын үстерү бүлеге начальнигы урынбасары;

юридик бүлек начальнигы;

юридик бүлек начальнигы урынбасары;

юридик бүлекнең әйдәп баручы киңәшчесе

юридик бүлекнең әйдәп баручы консультанты.”.

**Министр** **А.Р. Шәфигуллин**